КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1193

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтны билгеләү турында» 2015 ел, 18 ноябрь, 870 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтны билгеләү турында» 2015 ел, 18 ноябрь, 870 нче карарына, 1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акционерлык җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр «Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын бирү йөкләмәсеннән азат ителгән очракта, әлеге предприятиеләр һәм җәмгыятьләр белән мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына тапшырылган еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгындагы, шулай ук әлеге предприятиеләр һәм җәмгыятьләр тарафыннан тапшырылган квартал, яртыеллык, тугыз айлык арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгындагы.».

2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин